| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2018 Казан ш. № 5-96/тэ

«Казэнерго» акционерлык җәмгыятеннән җылы белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, «Казэнерго» акционерлык җәмгыятеннән җылы белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2018№ 5-96/тэ карарына кушымта

«Казэнерго» акционерлык җәмгыятеннән җылы белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатында җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салучы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләштерүче пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см2 кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см2 кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см2 кадәр | югары 13,0 кг/см2 | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1190,25 | - | – | – | – | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1213,44 | - | – | – | – | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1213,44 | - | – | – | – | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1246,41 | - | – | – | – | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1246,41 | - | – | – | – | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1287,91 | - | – | – | – | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1287,91 | - | – | – | – | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1320,71 | - | – | – | – | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1320,71 | - | – | – | – | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1369,33 | - | – | – | – | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге